**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕКУЛЬГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422660, с. Большая Кульга ,
ул. Школьная , дом 11

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ОЛЫ КУЛЬГА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422660, Олы Кульга авылы,
Мэктэп урамы, 11 нче йорт,

Тел.: (84361) 29202, факс: (84361) 29202, e-mail: Bklg.Rs@tatar.ru


ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

31.01.2020 ел Олы Кульга авылы № 2

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Кульга авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 3 пунктын, 12 статьясындагы 3 пунктын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карарының 3 пункты нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Кульга авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә 6124,86 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1,2 кушымталар нигезендә, 2020 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Кульга авыл җирлегенең «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Кульга авыл (шәһәр) җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» гы 06.05.2019 елның 13 нче номерлы карарын 2020 елның 1 нче февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Кульга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Кульга авылы, Мәктәп урамы, 11 йорт; Кече Кульга авылы, Беренче май урамы, 1 йорт; Дон-Урай авылы, Бакча тыкрыгы, 2 йорт; Олы Осиновка авылы, Кооператив урамы, 1 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе
муниципаль районы Олы Кульга
авыл җирлеге башлыгы Е.А.Терентьев

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕКУЛЬГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлеге Башкарма комитетының 31.01.2020 елның 2 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Кульга авыл җирлегендә җирләү буенча 2020 елның 1 февраленнән күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча хезмәт күрсәтү бәясе**

| Хезмәт күрсәтүнең исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк- яракларны бирү һәм китерү | 2230 |
| 3. Мәетне (гәүдә калдыкларын) зиратка (крематорийга) илтү | 1020 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү), кремацияләнгән мәет калдыклары | 2874,86 |
| Барлыгы: | 6124,86 |

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлеге Башкарма комитетының 31.01.2020 елның 2 номерлы карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирләү буенча Олы Кульга авыл җирлегендә хатыны, якын туганнары, башка туганнары яисә үлгән затның законлы вәкиле булмаганда яисә җирләүне гамәлгә ашыру мөмкин булмаганда яисә җирләү бурычын үз өстенә алган бүтән зат булмаганда күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча түләүсез күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе**

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү, киендерү | 485 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк-яракларны бирү һәм китерү | 1745 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәд калдыкларын) зиратка илтү | 1020 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2874,86 |
| Барлыгы | 6124,86 |